КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 сентябрь г.Казань № 623

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының «Әтиләр советы эшчәнлегенең иң яхшы оешмасы» социаль проектлар республика конкурсы турында

Әти-әниләр җәмгыяте эшчәнлегенә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү, гаилә кыйммәтләренең дәрәҗәсен ныгыту һәм әти статусын күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советының Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында «Әтиләр советы эшчәнлегенең иң яхшы оешмасы» социаль проектлар республика конкурсын үткәрү һәм аны үткәрүне оештыру-техник тәэмин итү турында тәкъдимен кабул итергә.

2. 2016 елның 1 октябреннән 8 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының «Әтиләр советы эшчәнлегенең иң яхшы оешмасы» социаль проектлар республика конкурсын үткәрергә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының «Әтиләр советы эшчәнлегенең иң яхшы оешмасы» социаль проектлар республика конкурсы турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының «Әтиләр советы эшчәнлегенең иң яхшы оешмасы» социаль проектлар республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков